| | |
|---|---|
| ГЛАВА РОДНИКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>РОДНИКИ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

с. Родники

30.10.2019 № 7

**Алексеевского муниципаль районының**
**“Родники җирлеге территориясендәге Родники авылында**
**үзара салым кертү һәм гражданнарның үзара салым акчаларыннан**
**файдалану мәсьәләсе буенча**
**гражданнар җыенын билгеләү турында “**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ” Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында “Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы», Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә,

**Карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районының Родники җирлеге территориясендәге Родники авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2019 елның 12 нче ноябре көнне 14 сәг 00 минутта гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
Алексеевск муниципаль районы Родники җирлеге территориясендәге Родники авылында 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, үзара салымны, барлык шул җирлек территориясендә теркәлгән, балигъ булган затлардан, хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку бүлеге студентларыннан тыш, җыюга һәм акчаларны җирле түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы?

- җирлек эчендәге юлларга вак таш җәю, төзекләндерү һәм карап тоту;
- Родники авылында Гагарин урамы буенча эчәргә яраклы кое төзү;
- балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру;

“ ӘЙЕ " КАРШЫ”

3. Халык җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Җыенның үткәрү урыны дип авыл клубын йортын билгеләргә. Адресы: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Родники авылы, Совет урамы, 3 йорт.

5. Әлеге карарны Родники авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Родники авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** **Е.А. Яковлева**